ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 10 » декабрь 2024 ел** **№ 18**

**Арча муниципаль районы
"Яңасала авыл җирлеге"
муниципаль берәмлегендә
гражданнардан үзара салым
акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 08 августындагы 52 номерлы Яңасала авыл җирлеге Советы карары нигезендә, 14.11.2024 N3, 14.11.2024 N4 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы "Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Р, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк ур., 18 йорт; ТР, Арча районы, Каенсар авылы, Урта ур., 25 йорт.

3. "Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2023 елның 14 декабрендәге 24

номерлы Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Яңасала авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе

А.И.Сафин

Яңасала  авыл җирлеге
башкарма комитетының
«10» декабрь 2024 ел, №18
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы "Яңасала  авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Яңасала  авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Яңасала  авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2024 елның 15 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә белем алучы студентлар,

б) 1 төркем инвалидлар,

в) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен түләүләр күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Яңасала  авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап

оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгәндә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Яңасала  авыл җирлеге
башкарма комитетының
«10» декабрь 2024ел, №18
карарына  2 нче кушымта

**Яңасала  авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N _______________**

Түләүченең Ф.И.А.и_____________________________________________
Адресы:_________________________________________________________
Нигезе__________________________________________________________
Сезгә _________________________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү______________________________________ суммада ______________ сум түләргә  кирәк.
түбәндәге реквизитлар буенча:____________________________________
алучының банкы БИК _____________________________
Сч. N ________________________________________
Алучы Сч. N ________________________________
ИНН ______________________________________________
КПП ______________________________________________
КБК __________________ОКАТО ___________________
Түләүнең билгеләнеше _________________________________________________________________

Җитәкче __________________ ___________________________________________
М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Яңасала  авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__
суммада _________________ сум
Түләүченең Ф. и.а.и. _____________________________________________
Адресы: _______________________________________________________
Алдым "___" ________________ 20__ ел ___________________________
(түләүченең имзасы /ФИАи)

**Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек тамыр тутырыла һәм Яңасала  авыл җирлеге Башкарма комитетында кала**